КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 октябрь г.Казань № 923

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1.1 пункт таблицасының 8 пунктында «Мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «Шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.1 пункт таблицасының 8 пунктында «Мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «Шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.1 пункт таблицасының 8 пунктында Мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «Шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ» сүзләренә алмаштырырга;

4.4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Акылга зәгыйфь балалар өчен интернат-йортларда, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат-йортларда, даими урын режимында булган һәм паллиатив ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтүләрнең исемнәре, тасвирламасы, күләме, сыйфаты һәм нәтиҗәләрен бәяләү күрсәткечләре әлеге Тәртипкә 8 нче кушымтада күрсәтелгән.»;

4.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.2. Социаль хезмәт күрсәтү вакыты социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы белән билгеләнә.

18 яшькә җиткән социаль хезмәт алучылар акылга зәгыйфь балалар өчен интернат-йортларда, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат-йортларда яшәүләрен һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне индивидуаль программа нигезендә социаль хезмәтләр алуны дәвам итәргә хокуклы:

алар белем бирү оешмасында укуын тәмамлаганчы, әмма 23 яшьтән артык түгел;

18 яшькә җиткән социаль хезмәт алучылар, даими урында яту режимында булган һәм паллиатив ярдәмгә мохтаҗ, әмма 30 яшьтән артык түгел.»;

Тәртипкә 1 нче кушымтаның «Картлар һәм инвалидлар интернат йортларында (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү һәм аларның сыйфаты күрсәткечләре» таблицасында «Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру» юлының 5 графасында «25» саннарын «85» саннарына алмаштырырга;

Тәртипкә 2 нче кушымтаның «Психоневрология интернатларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү һәм аларның сыйфаты күрсәткечләре» таблицасында «Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру» юлының 5 графасында «25» саннарын «85» саннарына алмаштырырга;

Тәртипкә 3 нче кушымтаның «Акыл үсеше артта калган балалар өчен интернат-балалар йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү һәм аларның сыйфаты күрсәткечләре» таблицасында «Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру» юлының 5 графасында «25» саннарын «85» саннарына алмаштырырга;

Тәртипкә 4 нче кушымтаның «Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең социаль-тернәкләнерү бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү һәм аларның сыйфаты күрсәткечләре» таблицасында:

«Күрсәтелгән социаль хезмәтләрдә социаль хезмәтләр алучыларның канәгатьлелеге» юлының 5 графасында «100» саннарын «80» саннарына алмаштырырга;

«Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру» юлының 5 графасында «25» саннарын «85» саннарына алмаштырырга;

Тәртипкә 5 нче кушымтаның ««Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү һәм аларның сыйфаты күрсәткечләре» таблицасында:

«Күрсәтелгән социаль хезмәтләрдә социаль хезмәтләр алучыларның канәгатьлелеге» юлының 5 графасында «100» саннарын «80» саннарына алмаштырырга;

«Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру» юлының 5 графасында «25» саннарын «85» саннарына алмаштырырга;

Тәртипкә 6 нчы кушымтаның«Билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, тасвирламасы һәм аларны социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында күрсәтү күләмнәре» таблицасында:

«Күрсәтелгән социаль хезмәтләрдә социаль хезмәтләр алучыларның канәгатьлелеге» юлының 5 графасында «100» саннарын «80» саннарына алмаштырырга;

«Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру» юлының 5 графасында «25» саннарын «85» саннарына алмаштырырга;

Тәртипкә 7 нче кушымтаның «Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында 18 яшьтән алып 23 яшькәчә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү һәм аларның сыйфаты күрсәткечләре» таблицасында «Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру» юлының 5 графасында «25» саннарын «85» саннарына алмаштырырга;

Тәртипкә 8 нче кушымта өстәргә (кararга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында
социаль хезмәтләр күрсәтү
белән тәэмин итүчеләр
тарафыннан социаль хезмәт
күрсәтүнең стационар
формасында социаль
хезмәтләр күрсәтү тәртибенә
8 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 17 октябрь, 923 нче
карары редакциясендә

Акылга зәгыйфь балалар өчен интернат-йортларда, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат-йортларда, даими урын режимында булган һәм паллиатив ярдәмгә мохтаҗ социаль хезмәтләрне алучы 18 яшьтән алып балалар өчен социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтүләрнең исемнәре, тасвирламасы, күләме, сыйфаты һәм нәтиҗәләрен бәяләү күрсәткечләре

| Т/с | Социаль хезмәт күрсәтү исеме | Социаль хезмәт күрсәтү тасвирламасы | Социаль хезмәт күрсәтү күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | үлчәү берәмлеге | саны | күрсәтү ешлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Социаль-көнкүреш хезмәтләр күрсәтү: | | | | |
| 1.1. | Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү, шул исәптән: | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга социаль-көнкүреш, социаль-медицина, социаль-педагогик, социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтү | кв.метр | 21 | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 1.1.1. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә | Торак мәйдан күләмнәре һәм башка яшәеш күрсәткечләре (урынның торышы һәм | | | социаль хезмәт күрсәтү чоры |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | торак урыннар мәйданнарын бирү | уңайлылыгы) буенча санитария-гигиена нормаларына туры килергә һәм клиентларның яшәү уңайлыгын тәэмин итәргә тиеш: | | | |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга 2 һәм аннан да күбрәк койка-урынлы бүлмәдән торак мәйдан бирү | кв.метр | 6 | |
| 1.2. | Торак урыннарны җыештыру | Урыннарны санитария-гигиена ягыннан эшкәртү, шул исәптән: | эшкәртү | | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | җилләтү; | | 2 | көнгә |
| | | идән юу; | | 2 | көнгә |
| | | стеналарны, ишекләрне юу; | | 1 | көнгә |
| | | йомшак өслекләрне тузан суырткыч белән тузаннан чистарту; | | 1 | көнгә |
| | | тәрәзә төпләрен, рамнарны, җиһазларны, көнкүреш приборларын, җылыткыч батареяларын | | 1 | көнгә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | юу; | | | |
| | | раковинаны, унитазны, ваннаны чистарту, дезинфекцияләү | | 1 | көнгә |
| | | Гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру, шул исәптән юу: | җыештыру | | |
| | | туклану урыннарындагы идәннәрне; | | 4 | көнгә |
| | | коридорлардагы идәннәрне; | | 2 | көнгә |
| | | бәдрәфләрне, душ, ванна бүлмәләрен; | | 2 | көнгә |
| | | тернәкләндерү һәм дәвалау чараларын, дәвалау-хезмәт һәм уку-өйрәтү эшчәнлеген, мәдәни һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру урыннарындагы идәннәрне; | | 1 | көнгә |
| | | тәрәзә пыялаларын һәм рамнарын | | 1 | айга |
| | | Тәрәзәләрне, балкон һәм керү ишекләрен көзге-кышкы һәм язгы-җәйге чорларда эксплуатацияләүгә әзерләү (җылыту, герметиклардан чистар- | әзерләү | 2 | елга |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ту). | | | |
| | | Якын-тирә территорияне чүп-чардан (кардан) чистарту | чистарту | 1 | көнгә |
| 1.3. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә йомшак инвентарь һәм санитария-гигиена билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин итү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыны йомшак инвентарь (карават янына җәелә торган палас, сөлге, урын-җир әйберләре), санитария-гигиена билгеләнешендәге товарлар (туалет кәгазе, юа торган чаралар), өс киемнәре һәм аяк киемнәре белән тәэмин итү. Өс киемнәре һәм аяк киемнәре, сезонга карап, клиентның буе һәм үлчәме буенча сайлана. Йомшак инвентарь файдалануда уңай булырга, клиентларның физик хәлен исәпкә алып сайланырга тиеш. Йомшак инвентарь белән тәэмин иткәндә шулай ук урын-җир әйберләрен, өс | данә (комплект) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә | социаль хезмәт күрсәтү чоры |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | киемнәрен юу, киптерү, үтүкләү, киемнәрне, урын-җир әйберләрен һәм эчке киемнәрне дезинфекцияләү, урын-җир әйберләрен (матрац, юрган, мендәр, япма) дезинфекцияләү, шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы социаль хез-мәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчедән киткәннән соң урын-җир әйберләрен алыштыру, тернәкләндерүнең шәхси техник чараларын, протезларны, ортезларны һәм башкаларны карауда ярдәм күрсәтү, аяк киемнәрен үзәкләштереп ремонтка бирү | | | |
| 1.4. | Сәламәтлекләренең торышы буенча мөстәкыйль рәвештә үз-үзләренә гигиена хезмәтләре күрсәтә алмаган затларга | Эчке киемнәрне алыштыру | смена | кимендә 1 тапкыр | көнгә (социаль хезмәт күрсәтү чорында) |
| | | урын-җирен алыштыру | смена | кимендә 1 тапкыр | атнага һәм пычрануына карап (социаль хезмәт күрсәтү чорында) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | аларны күрсәтү | индивидуаль хезмәт күрсәтү һәм гигиена характерындагы социаль-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән: | хезмәтләр күрсәтү | даими | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | киенгәндә (чишенгәндә) ярдәм итү | хезмәтләр күрсәтү | 4 раза | көн саен һәм пычрануына карап |
| | | авыз куышлыгын юдыру | хезмәтләр күрсәтү | 2 | көнгә |
| | | чәчләрен тарау | хезмәтләр күрсәтү | 1 | көнгә |
| | | чәчтараш хезмәтләре күрсәтүне оештыру | хезмәтләр күрсәтү | 1 | айга |
| | | тырнакларын кисү | хезмәтләр күрсәтү | 1 | атнага |
| | | авыз куышлыгын, борын куышлыгын, күзләрен, колакларын юдыру, медицина препаратлары белән эшкәртү | хезмәтләр күрсәтү | 1 | көнгә |
| | | тәнне өлешчә чистарту (юеш сөлге белән сөртү, юу, гигиена ванналары | хезмәтләр күрсәтү | 1 | көнгә |
| | | тәнне тулысынча чистарту: ятып кына торучы авыруны мунчада (ваннада, душ- | хезмәтләр күрсәтү | 1 | атнага |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | та) тулысынча юындыру | | | |
| | | памперсларны алыштыру | смена | 4 | көнгә һәм кирәк булуга карап |
| | | катетерлардан һәм башка медицина әйберләреннән файдалануда ярдәм итү | хезмәтләр күрсәтү | факт буенча | көн саен |
| | | караватта позиция алу, күчереп утырту (күчереп утыртканда ярдәм итү), позиция бирү креслоларына утырту | хезмәтләр күрсәтү | 7 | көнгә |
| 1.5. | катетерлардан һәм башка медицина әйберләреннән файдалануда ярдәм итү | Кайнар аш сыйфатлы продуктлардан әзерләнергә, калориясе буенча клиент-лар ихтыяҗын канәгатьлән-дерергә, туклануның билгеләнгән нормаларына, санитария-гигиена таләп-ләренә туры килергә һәм социаль хезмәт-ләр күрсәтүдән файдаланучы-ның сәламәт-леге торышын исәпкә алып күрсәтелергә тиеш | ризык ашау | 5 | тәүлектә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.6. | Ризык кабул итәргә булышу (ашату) | Оештырылган туклану вакытында ашату | ашату | кирәк булганда | тәүлектә |
| 1.7. | Медицина оешмаларына транспортка утыртып алып баруны оештыру | Кичектергесез медицина ярдәме күрсәтергә кирәк булганда йә дәвалау учреждениесенә салу таләп ителә торган авыру килеп чыкканда госпитальләштерүдә булышлык күрсәтү | ашыгыч медицина ярдәмен чакыру яисә дәвалау-профилактика учреждениесенә илтү | күрсәткечләр буенча | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 2. | Социаль-медицина хезмәтләре күрсәтү: | | | | |
| 2.1. | Табиб тарафыннан медицина каравын үткәрү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының сәламәтлеге торышын объектив билгеләү максатларында хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен яраганлык күрсәткечләре булу (булмауны) ачыклау буенча беренчел медицина каравын үткәрү | караулар | 1 | айга (социаль хезмәт күрсәтү чорына) |
| 2.2. | Табиб билгеләве буенча медицина процедуралары үткәрү | Дару тамызу; тәнне сылау; горчичниклар, компресслар кую; дару препаратларын тире астына һәм мускул эченә кертү; яраны эшкәртү | процедуралар | табиб билгеләве буенча | социаль хезмәт күрсәтү чоры |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | һәм бәйләү; суелган урыннарны эшкәртү | | | |
| 2.3. | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы-лар сәламәт-легендәге тай-пылышларны ачыклау өчен аларны систе-малы рәвештә күзәтеп тору | Шәфкать туташы тарафыннан карау (сәламәтлек торышын күзәтү) | караулар | 2 | көнгә |
| 2.4. | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы-лар сәламәт-леге торышын күзәтүгә бәйле булган проце-дуралар үткәрү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның сәламәтлеге торышын күзәтүгә бәйле булган процедуралар үткәрү: | | | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | тән температу-расын үлчәү; | процедура-лар | күр-сәткечләр буенча | |
| | | артериаль кан басымын үлчәү; | процедура-лар | күр-сәткечләр буенча | |
| | | дарулар кабул итүне тикше-рүдә тоту | процедура-лар | табиб билгеләве нигезендә | |
| 2.5. | Савыктыру чараларын үткәрү | Иртән гимнастика ясауны, саф һавада йөреп керүне, һава ванналарын | чаралар комплексы | 1 | көнгә (социаль хезмәт күрсәтү чорына) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | кабул итүне оештыру | | | |
| 3. | Социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтү: | | | | |
| 3.1. | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның документларын рәсмиләштергәндә һәм яңадан алганда булышлык күрсәтү | Карамакларында кирәкле мәгълүматлар булган оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән документларны яңадан алуда булышлык күрсәтү | хезмәтләр | кирәк булуга карап | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 3.2. | Юридик хезмәтләр күрсәтүдән файдаланууда ярдәм итү | Законнарда билгеләнгән тәртиптә түләүсез юридик ярдәм, шул исәптән адвокат ярдәмен алуда булышлык күрсәтү | хезмәтләр | кирәк булганда | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 4. | Тереклек эшчәнлекләре чикләнгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында хезмәтләр күрсәтү: | | | | |
| 4.1. | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль-тернәкләндерү чараларын үткәрү | Тактик хисселек, күрү сәләтен үстерү, хәрәкәт активлыгын стимуллаштыру, ишетү игътибарын үстерү өчен дәресләр үткәрү | чаралар комплексларын | 2 | атнага (социаль хезмәт күрсәтү чорына) |

Акылга зәгыйфь балалар өчен интернат-йортларда, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат-йортларда, даими урын режимында булган һәм паллиатив ярдәмгә мохтаҗ социаль хезмәтләрне алучы 18 яшьтән алып балалар өчен социаль

хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәләренең күрсәткечләре һәм аларны бәяләү

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Хисаплап чыгару формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик мәгънәсе | Индикаторның авырлык коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Оешмада социаль хезмәт күрсәтүдә булган социаль хезмәтләр алучыларның гомуми санында социаль хезмәтләр алучы социаль хезмәт алучылар өлеше | процент | $\frac{КН}{КП} \times 100$, монда: КН – контроль-күзәтчелек органнары күрсәтмәләрендә теркәлгән хокук бозулар саны; КП – контроль-күзәтүче органнарны тикшерүләр саны | тикшерү акты | 0 | 8 |
| Оешмада социаль хезмәт күрсәтүдә булган социаль хезмәтләр алучыларның гомуми санында социаль хезмәтләр алучы социаль хезмәт алучылар өлеше | процент | $\frac{ПСУ}{ОПС} \times 100$, монда: ПСУ – социаль хезмәт күрсәтү оешмасында социаль хезмәтләр алучылар саны; ОПС – социаль хезмәт алучыларның гомуми санында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми саны | мониторинг системасы | 100 | 5 |
| Социаль хезмәтләр күрсәтүдән канәгать булган социаль хез- | процент | Сораштыру нәтиҗәләре нигезендә билгеләнә: | социаль хезмәтләр күрсәтүдән | 100 | 4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| мәтләр күрсәтүдән файдаланучылар өлеше | | $\frac{(Ок + Од)}{2 \times О} \times 100 = У$, монда: Ок – хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгать булган сораштырылучылар саны; Од – күрсәтелә торган хезмәтләрнең файдаланырлык булуыннан канәгать сораштырылучылар саны; О – социаль хезмәтләр алучыларның сораштырылганнарның гомуми саны | файдаланучыларны сораштыру нәтиҗәләре буенча | | |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче штатының белгечләр белән комплектлануы | процент | $\frac{УС}{ЧСШ} \times 100$, монда: УС – социаль хезмәт күрсәтү оешмасында эшләүче белгечләр саны ЧСШ – штат расписаниесе буенча белгечләр ставкалары саны | мониторинг системасы | 100 | 4 |
| Оешмада социаль хезмәтләр алуның мөмкинлеге | процент | Түбәндәгеләр буенча билгеләнә: | тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, | 80 | 5, шул исәптән: |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре турында актуаль мәгълүмат булу белән сайтта һәм мәгълүмати стендларда, социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче мониторларда; | мониторинг системасы | булу (20 процент) | 1 |
| | | социаль хезмәтләр | | булу | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | күрсәтелә торган объектлар (биналар, биналар) урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге булу; | | (20 процент) | |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтелә торган бинага тоткарлыксыз керү һәм бинага (бүлмәгә) чыгу мөмкинлеге булу, шул исәптән колясккалы кәнәфиләрне кулланып; | | булу (20 процент) | 1 |
| | | күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясен нык бозган инвалидларны озата бару өчен җаваплы хезмәткәрләр булу, шулай ук инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгу өчен ярдәм күрсәтү; | | булу (20 процент) | 1 |
| | | социаль хезмәт алучыларның тормыш-көнкүрешен чикләвне исәпкә алып мәгълүмат йөртүчеләрне урнаштыру | | булу (20 процент) | 1 |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру | процент | Социаль хезмәт күрсәтү вакытында оешма эшчәнлеген камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралардан чыгып билгеләнә: | мониторинг системасы | 70 | 8, в т.ч.: |
| | | грант алуга конкурста катнашу (ел саен); | мониторинг система- | булу (10 процент) | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | сы | | |
| | | грант алуга конкурста җиңү (ел саен); | монито-ринг система-сы | булу (10 про-цент) | 1 |
| | | социаль хезмәтләр сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре; | сыйфат бәйсез бәяләүне үткәрүгә эксперт бәяләмә-се | 85 балл-дан ким түгел (15 про-цент) | 1 |
| | | ачыкланган җитешсез-лекләрне бетерү; | монито-ринг система-сы | булу (10 про-цент ов) | 1 |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүнең расланган эчке сыйфат системасы; | монито-ринг система-сы | булу (15 про-цент) | 1 |
| | | социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә ведомство яки дәүләт контроле (күзәт-челеге) кысаларында хокук бозуларның булмавы; | тикшерү үткәрү турында акт | булу (15 про-цент) | 1 |
| | | яңа технологияләр, эш формалары һәм метод-ларын гамәлгә кертү; | монито-ринг система-сы | елга 1 дән ким түгел (10 про-цент) | 1 |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүче хезмәткәр-ләрнең квалифика-циясен күтәрү планын үтәү | монито-ринг система-сы | булу (15 про-цент) | 1 |